**Характеристика.**

Яшел Үзән районы
В.В.Карпов исемендәге лицейның
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Фатихова Лилия Рафил кызына.

Фатихова Лилия Рафил кызы В.В.Карпов исемендәге лицейда 2012 нче елдан бирле эшли. Безнең мәктәптә эшләү дәверендә ул үзен татар телен укытуның методикасын камил белүче белгеч, иҗади эшләүче укытучы итеп танытты. Лилия Рафил кызы заман педагогикасын һәм психологиясенең казанышларын оста файдалана белә. Аның дәрес үткәрү методлары төрле, алар фәнни юнәлештә, укучыларны укыту һәм тәрбияләүдә комплекслы якын килүгә нигезләнгәннәр. Лилия Рафил кызының дәресләре методик яктан дөрес төзелгән, укыту материалы тиешенчә сайланган, уку-укыту мәсьәләләре иҗади якын килеп укучыларның тирәнтен уйлау сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән. Дәесләрдә инновацион технологияләрне эффектив куллану укытучыга укытуда мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен фомалаштырырга, укучыларга дифференциаль якын килеп эшләргә мөмкинлек бирә. Укытучы үзенең эшендә төрле дәрес типлары белән эш итә ( дәрес-дискуссия, викторина, уен, сәяхәт, экскурсия һ.б.). Лилия Рафил кызы заманча укыту методларыннан оста файдалана, ул дәесләрдә интерактив такта ярдәмендә төрле презентацияләр куллана.

Укытучы үз-үзенә һәм укучыларга карата таләпчән, моны административ эш нәтиҗәләре дalилли. Бу нәтиҗәләр укучыларның белемнәре тирән, төпле булуын күрсәтә. 2014 елда укучыларның укуда үсеш дәрәҗәләре уңай якка үзгәргән 72 %тан 74 % кадәр үскән. Лилия Рафил кызының укучылары төрле конкурсларда актив катнашалар. Мәсьәлән, Укучыларның туган якны өйрәнү буенча VI фәнни-гамәли конференция "Карпов укулары"нда, 5 сыйныф укучысы Әскәрова Камилә II урынга лаек булды (2014), Каюм Насыйри исемендәге XIII Төбәкара яшүсмерләр фәнни-тикшеренү укуларында 10 сыйныф укучысы Яруллина Диләрә катнашты (2015), Сара Садыйкова исемендәге VIII регионара ачык конкурс-фестивале "Калфаклы сандугач"та 7 сыйныф укучысы Әскәрова Камилә катнашты (2015), Татар теленнән Бөтенроссия олимпиадасында (дистанцион) 7 сыйныф укучысы Ганибаев Адель I урынга лаек булды, «Минем яраткан укытучым» инша конкурсында 7 сыйныф укучысы Хусаинова Әлфия катнашты (2015)

Лилия Рафил кызы – сыйныф җитәкчесе. Ул укучылар коллективы белән оста җитәкчелек итә, һәр укучы белән уртак тел таба белә. Төрле тәрбияви

чаралар үткәргәндә класс активына һәм эти-әниләргә мөрәҗәгать итә. Аның сыйныфында укучылар дус, эш сөючән, мәктәп тормышында актив. Ул уку һәм тәрбия процессын оештырганда эти-әниләр белән бергә эшли. Гомуми ата-аналар җыелышында даими чыгышлар ясый. Сыйныф җитәкчесе буларак Лилия Рафил кызы укучыларында укуга һәм хезмәткә карата җаваплы караш тәрбияли. Ул укучыларны шәфкатьле, толерант, игелекле, мәрхәмәтле булырга өнди.

Лилия Рафил кызы укучыларга крата сабыр, гадел, укучы шәхесенә карата хөрмәтле укытучы. Ул үзенең профессиональ, тактлы, мәрхәмәтле шәхес булуы белән укучыларының, эти-әниләренең, коллегаларының хөрмәтен яулаган укытучы.

Мәктәп директоры: Королёва Э.Н.